РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31.10.2024 Буа шәһәре № 314 Бк/к

Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру һәм «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2018 ел ның 24 апрелендәге № 111/ик-п номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары җитәкчеләренә, белгечләренә һәм хезмәткәрләренә социаль гарантияләр тәэмин итү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Министрлар Кабинетының 2024 елның 21 сентябрендәге 820 номерлы «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында» һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 30 мартындагы 195 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары нигезендә Буа муниципаль районы башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2025 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оеш-

малары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 ел ның 24 апрелендәге № 111/ик-п номерлы карары белән (Буа муниципаль районы Башкарма комитетының 27.01.2022 № 18/Бк/к, 31.10.2022 № 331/Бк/к 13.12.2022 № 390/Бк/к, 24.05.2024 №139/Бк/к карарлары ред) белән кертелгән үзгәрешләр белән билгеләнгән тәртиптә билгеләнә торган бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттырырга.

2.Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладлары күләмнәрен исәпләп чыгару өчен, әлеге карарның 1 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган муниципаль берәмлекләрдә бюджет өлкәсенең аерым оешмасы структур бүлекчәсе җитәкчесе секретареның вазыйфаи окладлары күләмен 1,05 мәртәбә индексацияләргә һәм аны 13 990 сум күләмендә билгеләргә.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында түбәндәге адрес буенча урнаштырылырга тиеш: https://buinsk.tatarstan.ru/.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкче Л.Р. Шакирҗанов